**Бер очрашу-бер гомер!**

Добавил(а) Administrator
жомга, Март 11, 2016 12:00




Ниһаять, бvген мәктәбебездә кvптән котелгән очрашу. Очрашуга дип, ерак араларны якын итеп, Гарифуллин Васил Заһит улы, Галиева Рәсимә Муллаян кызы (КФУнын татар журналистикасы кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты, "Ватаным Татарстан" газетасы корреспонденты) һәм районыбыз вәкилләре килде. "Бер очрашу - vзе бер гомер!" дип исемләнгән бу кичә кvнелләрдә жылы хисләр тудырды. Васил Заһит улы

укучыларны КФУга укырга керv шартлары белән таныштырды, республикабызда журналистиканын торышы турында сойләде, укучыларнын сорауларына жаваплар бирде, журналистика факультетына укырга керергә чакырды, мәктәп китапханәсенә китаплар бvләк итте. Шулай ук vзенен мәктәптә укыган кызыл галстуклы пионер вакытында, авылыбыз янәшәсеннән агучы ямьле Мишә елгасы буенда vткәрелә торган районкvләм слетка килгән вакытларын сагынып искә алды, хатирәләре белән уртаклашты. Укучылар vз чиратларында кунакларга vзләре ижат иткән шигырьләрен сойләделәр, матур концерт номерлары кvрсәттеләр. Очрашу мизгелләре кvнелләрдә озак сакланыр.{jcomments on}